РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КАРАМАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АЗНАКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ул. Центральная, д 8, с.Карамалы,
Азнакаевский муниципальный район
423301

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КАРАМАЛЫ АВЫЛ
ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

Үзәк ур., 8 нче йорт, Карамалы
авылы, Азнакай муниципаль районы,
423301

Тел./факс(885592)4-56-42; E-mail:Karam.Azn@tatar.ru


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от « 11 » апреля 2019 года № 27

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Башкарма комитеты 13.11.2017 ел № 21 карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлегендә территорияне планлаштыру буенча документлар әзерләү Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында (15.05.2018 ел №11 карары нигезендә)

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Башкарма комитеты 13.11.2017 ел № 21 карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлегендә территорияне планлаштыру буенча документлар әзерләү Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында (15.05.2018 ел №11 карары нигезендә), «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлегендә территорияне планлаштыру буенча документлар әзерләү Тәртибенә » түбәндәге үзгәрешләрене кертергә:

1.1. түбәндәге эчтәлекле 2.1 пункт өстәргә:

«"Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 45 статьясындагы 1.1 өлешендә күрсәтелгән территорияне планлаштыру буенча документларны әзерләү очрагында Башкарма комитет тарафыннан территорияне планлаштыру буенча документлар әзерләү турында карар кабул итү таләп ителми»;

1.2. 2.4 пунктта «тиеш» сүзен «итәргә тиеш» сүзенщ алмаштырырга;

1.3. 2.5 пунктының 2 пунктчасын киләсе редакциядә бәян итәргә: дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр,

хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе Законы нигезендә төзелгән дәүләт, муниципаль (бюджет һәм Автоном) учреждениеләрнең ведомство буйсынуындагы органнарына яисә алар тарафыннан дәүләт яисә муниципаль контракт нигезендә җәлеп ителә торган, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 45 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган очраклардан тыш;

11.4. 2.9 пунктында «ачык тыңлаулар» сүзләрен «иҗтимагый фикер алышулар яки ачык тыңлаулар» сүзләренә алмаштырырга»;

1.5. 2.10 пунктының 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару өчен коммерциягә карамаган бакчачылык ширкәтенә бирелгән җир кишәрлеге чикләрендә территорияләр»;

1.1. 2.15 пунктында «ачык тыңлаулар» сүзләрен «җәмәгать фикер алышулары яки ачык тыңлаулар» сүзләренә алмаштырырга»;

1.7. түбәндәге эчтәлекле 2.15 пункт өстәргә:

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 45 статьясындагы 1.1 өлешендә күрсәтелгән затлар тарафыннан әзерләнгән территорияне планлаштыру буенча документларны кире кагу һәм аны эшләп бетерү өчен җибәрү өчен нигез булып мондый документларның Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 45 статьясындагы 10 өлешендә күрсәтелгән таләпләргә туры килмәве тора. Башка очракларда территорияне планлаштыру буенча мондый затлар тарафыннан тәкъдим ителгән документларны кире кагу рөхсәт ителми.».

1.8. пункты 2.11, 2.12, 2.13 признать утратившими силу и исключить;

1.9. 2.14, 2.15, 2.16, 2.17 пунктларны 2.11, 2.12, 2.13, 2.14 пунктлары дип санарга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru. урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http//aznakayevo.tatar.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

Башлык Ногманов А.Р.